ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
РУС САРСАЗЫ АВЫЛЫНДА ХАЛЫК ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 22 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Рус Сарсазы авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 нче елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Рус Сарсазы авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган үзара салым акчасын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Рус Сарсазы авылында урамнарны яктырту өчен светодиод яктырткычлар сатып алуга юнәлдерергә.
3. Әлеге карарны мәгълүмат стендына түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Рус Сарсазы авылы, Урман урамы, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Тойгуҗа
авыл җирлеге башлыгы Сафин Р.А.